# Караш

…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№2 2015. октябрь
Лашман урта мәктәбе укучылар комитеты органы
УКЫТУЧЫЛАР БӘЙРӘМЕНӘ БАГЫШЛАНГАН МАХСУС ЧЫГАРЫЛЫШ

## *5 нче октябрь – Халыкара укытучылар көне.*

Һәрбер кеше дә диярлек гомеренең унбер елын мәктәптә үткәрә. Анда ул укый, яза, белем ала. Тупланган белемнәре белән уку йортына керә. Аны тәмамлап эшкә урнаша, тормышта үз юлын таба. Һәм боларның барысы белән дә үзенә юл күрсәтүче – укытучыга бурычлы. Бер яктан укытучы бер гади профессия кебек: укучылардан үткән теманы сорыйсың, "5" яки "2" куясың, дәрес аңлатасың, һәм шуның белән бетте. Ләкин бу эшкә тирәнрәк карасаң, аның бик күп авыр якларын күрергә була. Беренче укытучыбыз безне кулга каләм тотып язарга, хәрефләр җыеп укырга, санарга өйрәтә. Башлангыч сыйныфларны тәмамлагач һәр предметтан аерым укытучы укыта башлый, монда аларның зур профессиональлеге таләп ителә. Һәрбер укытучы журналга билге куяр өчен түгел, ә укучылар ни дә булса аңлап калсын өчен тырыша. Мәктәптән кайткач та ул дәфтәрләр тикшерә, киткән хаталар өчен борчыла, икенче көнгә дәрескә әзерләнә, һәм һәр укучыга һәрвакыт бары яхшы теләкләрдә генә кала.

Сүземне тәмамлап барлык укучылар исеменнән шуны әйтәсем килә: без яраткан сыйныф җитәкчеләребезне, мәктәбебездә озак еллар укучыларга белем бирүче һәм яңа гына килгән укытучыларны – барыгызны да бу һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез, сезгә нык исәнлек, гаилә бәхете, олы сабырлык, зур уңышлар телибез. Сезнең хезмәтегез бәяләп бетергесез. Бәйрәмегез белән хөрмәтле укытучыларыбыз!

«Караш» ның иҗат төркеме

Әле кичә генә шушы мәктәптә укучылар идек. Журнал тотып сыйныф бүлмәсенә килеп кергән укытучы абый-апаларны басып сәламли, икеле алмас өчен тиз-тиз үткән дәресне кабатлый, бар көчкә ашханәгә чаба, аннары баш иеп линейка алдында тора идек. Әле кичә генә кебек… Ләкин шул инде 11 елдан артык вакыт узган. Кайчандыр укучы сыйфатында ашыга-ашыга йөргән коридордан инде укытучы булып, журнал тотып дәрескә керәбез. Ай-һай, җиңел түгел икән бу хезмәт! Ләкин янында үзеңнең укытучыларың булганда һич тә зарланырга ярамый. Эш барышында нинди дә булса кыенлык туса, "Тукта әле, теге вакытта безнең класста да шундый бер хәл булган иде бит, Тәслимә апа ничек эшләгән иде соң әле" – дип, уйлыйсың. Дәрестә бераз сыешалмый башласаң, Халидә апа, Кадрия апа дәресләрен искә төшерәсең, оялып та китәсең – бит алар хәтта 36 балалы сыйныф белән өлгерә иделәр, аңлата да, мавыктыра да белә иделәр. Балалар синең дәресеңдә кызыксынмый утырсалар капылт итеп Фаиз абый дәресләре күз алдына килеп баса… Әйе, чын остазлар укытты шул безне. Хөрмәтле укытучыларым! Сезне барыгызны да һөнәри бәйрәм белән тәбрик итәм. Бездән соң килгән буыннар да һаман сезне шулай сагынып, яратып искә алсыннар. Зур уңышлар, нык исәнлек, гаилә бәхете сезгә юлдаш булсын!

1998 нче елгы чыгарылыш укучысы Ралия Газыймҗанова

### *Фәния апа, сезне сагынам…*

Безнең мәктәптә укытучылар күп. Мин аларның барысын да бик хөрмәт итәм. Безне инде бик күп укытучы укытты. Ләкин алар арасында минем иң яраткан укытучым – Зөлфия апа. Ул бөтен укытучылардан да аерылып тора. Ул үзенә бер төрле акыллы, мөлаем… Мин аның орышканын, я булмаса такта янында бастырып торганын, зарланганын хәтерләмим. Әллә шуңа күрә аерым яратам микән аны? Ә бит кайбер укытучылар аз гына бер нәрсә булса да директорга әйтәм, әниеңә сөйлим дип кенә торалар. Ә Зөлфия апа директорга бармый, әнигә дә зарланмый иде.

Ерошкина Елена 7 нче сыйныф

### *Беренче укытучым.*

Минем беренче укытучым Есенаманова Илүзә апа. Ул безне беренче сыйныфтан дүртенче сыйныфка кадәр укытты. Безне хәреф танырга, язарга, санарга, тапкырларга, бүләргә һәм башка бик күп нәрсәләргә өйрәтте. Ул безне белемнең олы юлына ныклы әзерлек белән озатты. Мин аңарга бик зур рәхмәтемне белдерәм. Илүзә апа! Мең-мең рәхмәтләр сезгә!

Мухаметзянова Эвелина 5 нче сыйныф

Укытучы… Шушы сүзне ишетүгә без үзебезне укыткан укытучыларыбызны күз алдына китерәбез. Укытучы олы хөрмәт иясе. Мин үзебезнең сыйныф җитәкчесе Шәрига апа турында язарга телим. Сыйныф җитәкчесе икенче Әни бит ул. Җиде ел буена безне, җил-яңгыр тидермичә, яклар вакытта яклап, ярдәм кирәккәндә ярдәм итеп тәрбияләде Шәрига апа. Бар белемен, тырышлыгын кызганмыйча ул безне кеше итәргә тырышты, тормышта үз юлыбызны табарга, хокукларыбызны якларга өйрәтте.

Шәрига апа! Сезне бәйрәмегез белән котлап киләчәк көннәрегезгә ак бәхетләр, уңышлар телибез. Камил абый белән икәүләшеп Ак әби, Ак бабай булып тигез бәхет белән яшәгез! 11 нче сыйныфка кадәр тәрбияләвегез, чын мәгънәсендә икенче әни булганыгыз өчен ЗУР РӘХМӘТ сезгә!

Укытучы! Нинди бөек исем!
Киртә булмас аңа берни дә.
Һәрвакытта аңлый укучыны,
Һәрвакытта ярдәмгә килә.
Укытучым, сиңа сокланам мин.
Баш иямен олы хезмәтеңә,
Синең олы сабырлыгыңа.
Барысын сыйдырган йөрәгеңә.

*11 сыйныф исеменнән Ләйлә*

Тәслимә апа! Сез иң яхшы укытучы. Без сезне бөтенебез хөрмәт итәбез. Сез беркайчанда укучыга авыр сүз әйтмисез. Әллә нинди йөрәгегез яраланган вакытта да сабыр, мөлаем булып кала аласыз.безгә яхшы булса, сезгә дә яхшы,

Безгә авыр булса, сезгә дә бик авыр. Гел шундый әйбәт булып калыгыз!Без сезне бик яратабыз!

*9 нчы сыйныф укучылары.*

***Рушания апага.***

Анотомия, зоология,
Ботаника, физиология.
Бу фәннәрнең барысын да
Берләштерә биология.
Өйрәтә безгә аны
Рушания апабыз.
Дәресне әйбәт аңлата,
Рәхәтләнеп тыңлыйбыз.
Нәрсә, ничек булганын
Барысын да яхшы белә,
Ни генә сорасаң да
Дөрес җавабын бирә.
Үзе чибәр, мөлаем,
Җырлавы да бик моңлы,
Кайчандыр безне дә ул
Җырларга бит өйрәтте.
Ул өйрәткән биюләр
Һәрбер бәйрәмне бизи.
Рәхәтләнеп эшли ул,
Ару-талуны белми.
Оста бии, оста җырлый,
Бик яхшы укытучы,
Мәктәптә хөрмәт итә
Аны һәрбер укучы.
Без аны чын күңелдән
Бәйрәм белән котлыйбыз.
Исәнлек-саулык сезгә,
Булмасын һич кайгыгыз.
Эшегезне яратып,
Арымый башкарыгыз,
Озын гомерләр сезгә,
Бик бәхетле булыгыз!

*Закирова Миләүшә 11Б сыйныфы.*

***Минем яраткан укытучым.***

Мин мәктәптә яңа укучы. Минем өчен монда бөтенесе дә яңа. Ләкин инде вакыт агышы бөтенесен үзгәрткән. Монда минем иң яраткан укытучым – Гүзәлия апа. Ни өчен яратканымна да әйтә алмыйм. Матур итеп елмаюымы, укытуымы, үз итеп, яратып орышуымы? Белмим. Ул укыткан тарих дәресләре бик кызыклы үтә. Ул сөйләгәндә күз алдына хәрби походлар, патшаларның идарә итүләре ап-ачык килеп баса. Безнең белән дә ул бик ихлас, ягымлы. Гүзәлия апа кебек булыр идем мин!

Айрат 10 нчы сыйныф

…Мин үземнең мәктәбем белән горурланам. Безнең мәктәп бик матур, чиста, якты. Шушы матур мәктәптән чын кеше булып чыксыннар өчен укытучыларыбыз армый-талмый хезмәт куялар, үз көчләрен кызганмыйлар. Ә шулай да һәр укучының бер аерым үз иткән укытучысы була. Менә мин Халидә апа Дәүләтшинаны яратам. Ул безне татар теле һәм әдәбиятыннан укыта. Туган телебездә дөрес сөйләшергә, олыларны, кечеләрне хөрмәт итәргә өйрәтә. Ул һәрвакыт елмаеп, матур итеп сөйләшә. Аның сабырлыгына сокланам мин.

*Шәйхетдинов Илшат*
*10 нчы сыйныф*

Безнең мәктәптә укытучылар бик күп. Мин аларның барысын да бик хөрмәт итәм. Кайвакытта, дөрес әллә ниләр уйлаган чаклар да була. Менә син шундый кәеф белән сулышыңны "освежать" итеп "Дирол" чәйнәп утырасың. Беркемгә бәйләнмисең, тимисең… Ә укытучылар кара болыт кебек төшәләр. Мәңге исәнләшмәм , дисең, үз-үзеңә әллә нинди вәгъдәләр бирәсең. Әллә укытучылар сихерче микән? Чөнки берничә минуттан берни булмагандай үзең үк көлә-көлә сөйләшә башлыйсың. Тик гел көлешеп кенә утырып булмый ул. Менә бервакыт шулай татар теле дәресе башлана. Яраткан укытучыбыз Ралия апа керә, әй елмая инде, әй елмая. Без дә шат, димәк, апаның кәефе шәп, дәресне сорамаячак, сораса да икеле чәпәмәячәк. Ә Ралия апа елмая- елмая тактага "ДИКТАНТ" дип язып куя. Ә без еларга җитешеп эшкә керешәбез. Колакларны иркәләүче кыңгырау авазын гына көтәсе кала. Ә журналга икеле коела…

*Айнур 9 нчы сыйныф*